*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**
(2025-2026 нчы уку елы)
**11 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 44**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Ирен ассимиляциясе күзәтелгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) дүшәмбе
   ә) урманнар
   **б) унбер**
   в) көнгерә

2. Бирелгән омонимнарның төрен билгеләгез. **(2 балл)**
   ***Илгизәр – ил гизәр***
   а) саф омонимнар
   ә) омографлар
   б) омоформалар
   **в) омофоннар**

3. Тамыр, ясагыч һәм бәйләгеч кушымчадан торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) әнкәйне
   ә) кызчыклар
   **б) авылдашны**
   в) тоссыз

4. Билгеләү алмашлыгын билгеләгез. **(2 балл)**
   а) алар
   **ә) һәркайчан**
   б) ниндидер
   в) никадәр

5. Шигъри юллардагы калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең кайсы сүз төркеменә караганлыгын билгеләгез. **(2 балл)**
   *Туган илдән* ***киткән*** *сандугачлар*
   *Чит җирләрдә сайрый алмыйлар.* (Илдар Юзеев)
   а) сыйфат
   ә) хәзерге заман хикәя фигыль

б) үткән заман хикәя фигыль
**в) үткән заман сыйфат фигыль**

6. Җөмләнең хәбәрен билгеләгез. **(2 балл)**
*Һәр эшнең ахырын уйлап эшлә*. (Мәкаль).
а) эшнең
ә) уйлап
б) уйлап эшлә
**в) эшлә**

7. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең нинди җөмлә кисәге икәнлеген билгеләгез. **(2 балл)**
***Тырышкан*** *табар, ташка кадак кагар*. (Мәкаль).
**а) ия**
ә) аергыч
б) хәбәр
в) тәмамлык

8. Җөмләдәге иярчен компонентның мәгънә ягыннан төрен билгеләгез. **(2 балл)**
*Холкы начардан дуслары качар*. (Мәкаль).
а) иярчен ия җөмлә
ә) иярчен хәбәр җөмлә
б) иярчен аергыч җөмлә
**в) иярчен тәмамлык җөмлә**

## II. Теоретик бирем.

Төшеп калган сүзләрне языгыз. **(6 балл)**

Кайбер авазларны әйткәндә, **упкәдән** килә торган һава агымы **авыз** куышлыгында тоткарлыкка очрый, кайбер авазларны әйткәндә, тоткарлыкка очрамый. Язылышлары бердәй, әмма әйтелешләрендә аерма булган сүзләр **омографлар** дип атала. Кисәкчә, ымлык һәм модаль сүз – **модаль** сүз төркемнәре. Исемгә ияреп килгән җөмлә кисәге **аергыч** дип атала. **Синтетик** иярчен җөмлә иярчен кисәккә бик нык охшаган.

## III. Гамәли-иҗади бирем.

1. Сүзләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(6 балл)**

| | |
|---|---|
| *обычай – гореф-гадәт* | *попутчик – юлдаш* |
| *художник – рәссам* | *меч – кылыч* |
| *роса – чык* | *насекомое – бөҗәк* |

2. “Мин кем булырга телим?” дигән темага 12 җөмләдән торган инша языгыз. **(16 балл)**